КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1503

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» 2015 ел, 20 март, 177 нче карары белән расланган Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урнашкан урынны килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе эшенең бертип регламентына, 4 пунктта «, яшелчәчелек яисә дача» сүзләрен «яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өченче зат хокукларыннан азат булган ( хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибен раслау турында» 2016 ел, 25 май, 353 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 22 февраль, 114 нче, 2018 ел, 29 сентябрь, 882 нче, 2021 ел, 9 июнь, 443 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Өченче зат хокукларыннан азат булган (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү

инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга бирү өчен билгеләнгән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт исемлеген булдыру, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибенә, 2 пунктның «з» пунктчасында «яшелчәчелек, бакчачылык» сүзләрен «үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин